РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05.06.2019 № 80-п

“Сабан туе” татар халык бәйрәмен һәм билбау көрәше буенча дөнья Чемпионаты уздыру турында

Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 21 мартындагы 178-УП номерлы Указы нигезендә һәм 2019 елда районда “Сабан туе” татар халык бәйрәмен һәм билбау көрәше буенча дөнья Чемпионатын оешкан төстә үткәрү максатыннан

КАРАР БИРӘМ:

1. “Сабан туе” татар халык бәйрәмен һәм халык хуҗалыгы алдынгылары слетын авыл җирлекләрендә 2019 елның 8-9 июнендә, Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендә 2019 елның 16 июнендә, шулай ук билбау көрәше буенча дөнья Чемпионатын Мингәр авылында 2019 елның 23 июнендә уздырырга.

2. “Сабан туе” татар халык бәйрәмен һәм халык хуҗалыгы алдынгылары слетын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) төзергә һәм кушымтада каралганча аның составын расларга.

3. Комиссиягә тәкъдим итәргә:

- “Сабан туе” татар халык бәйрәмен һәм халык хуҗалыгы алдынгылары слетын әзерләү һәм уздыру буенча чаралар планын төзергә;

- спорт чаралары, халык уеннары, үзешчән сәнгатьтә катнашучыларның чыгышлары программасын төзергә:

- чыгымнар сметасын төзергә.

4. Тәкъдим итәргә:

4.1. Авыл җирлекләре һәм шәһәр җирлеге башлыкларына, авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать предприятиеләре, оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләренә, шәхси эшмәкәрләргә, оештыру-хокукый формалары һәм милек формаларына бәйсез рәвештә:

- профсоюз оешмалары белән берлектә “Сабан туе” татар халык бәйрәмен һәм халык хуҗалыгы алдынгылары слетын оешкан төстә үткәрүне тәэмин итүне һәм район Сабан туе программасына кергән спорт ярышлары, халык уеннары үткәрүне, җиңүчеләрне бүләкләүне оештыруны;

- район “Сабан туе” бәйрәме программасына кергән спорт ярышлары, халык уеннарында катнашу өчен командалар куюны, үзешчәннәрнең концерт программаларында катнашу өчен башкаручылар һәм алдынгыларны алып килүне оештыруны;

4.2. Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча бүлеге начальнигына бәйрәм чараларын әзерләү һәм үткәрү чорында бәйрәм чараларын уздыру урынында җәмәгатьчелек тәртибен саклауны, юл йөрү иминлеген һәм милек сакланышын тәэмин итүне оештыруны;

4.3. "Саба үзәк район хастаханәсе" дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибына чараларда катнашучыларга һәм халыкка медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итүне;

4.4. "Янгынга каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча 7нче отряды" федераль дәүләт казна учреждениесенең 129нчы янгын-коткару часте начальнигына бәйрәм чараларын әзерләү һәм үткәрү чорында материаль милекне һәм кешеләрнең гомерен янгын куркынычыннан саклауны тәэмин итүне;

4.5. "Татмедиа" акционерлык җәмгыятенең "Саба таңнары" газетасы редакциясе" филиалы баш редакторына һәм "Татмедиа" акционерлык җәмгыяте "Саба дулкыннары" телерадиокампаниясе филиалы директорына бәйрәм чараларына әзерлек һәм үткәрү барышын яктыртуны;

4.6. Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисенә бәйрәм чараларын үткәрүгә чыгымнар сметасы нигезендә акча чыганаклары бүлеп бирүне.

5. Оешма, предприятие, учреждение җитәкчеләренең, шәхси эшмәкәрләрнең, оештыру-хокукый формалары һәм милек формалары нинди булуга карамастан, район "Сабан туе" бәйрәмен һәм халык хуҗалыгы алдынгылары слетын үткәрү өчен матди ярдәм күрсәтү турындагы тәкъдимнәрен кабул итәргә.

6. Товарлар сатучы, җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтүче оешмаларны һәм шәхси эшмәкәрләрне "Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга салу һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчү) чикләү турында" 22.11.1995 ел, №171-ФЗ Федераль законы һәм "Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытына, шартларына һәм урыннарына өстәмә чикләүләр һәм алкогольле продукцияне сатуны тыю өлешендә Татарстан Республикасының кайбер закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында" 06.06.2015 ел, №10-ТРЗ Татарстан Республикасы Законын үтәү зарурлыгы хакында кисәтергә.

7. Әлеге карарны http://saby.tatarstan.ru. адресы буенча Саба муниципаль районы рәсми сайтында бастырып чыгарырга;

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны "Сабан туе" татар халык бәйрәмен һәм халык хуҗалыгы алдынгылары слетын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты рәисе М.Р. Кәримовка йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов

СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

Кушымта

Расланды:

Саба муниципаль районы Башлыгының

05.06. 2019 ел 80-п номерлы

карары белән

**“Сабан туе” татар халык бәйрәмен һәм халык хуҗалыгы алдынгылары слетын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру комитеты составы**

| | |
|---|---|
| Кәримов М.Р. | - Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары – Саба муниципаль районы Башкарма комитеты аппараты җитәкчесе, оештыру комитеты рәисе; |
| Котдусов И.И. | - Башкарма комитет Җитәкчесенең инвестицион үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм итү буенча урынбасары - инвестицион үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм итү бүлеге начальнигы, оештыру комитеты рәисе урынбасары; |
| Хәсәншин Г.Ш. | - Саба муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы, оештыру комитеты рәисе урынбасары; |
| Әгъзалар: | |
| Баһманов М.М. | - Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары; |
| Бикмөхәмәтов З.М. | - Саба аграр көллияте директоры (килешү буенча); |
| Билалова Р.К. | - “Россельхозбанк” ачык акционерлык җәмгыятенең Татарстан региональ филиалы Саба бүлекчәсе идарәчесе (килешү буенча); |
| Вәлиева Т.Р. | Саба муниципаль районы “Саба үзәкләштерелгән авыл клуб системасы” (Район мәдәният йорты) муниципаль бюджет учреждениесе культорганизаторы |
| Вәлиев Ф.Т. | - “Шәмәрдән ашлык кабул итү предприятиесе” ачык акционерлык җәмгыяте директоры (килешү буенча); |
| Вәлимөхәммәтова Ф.Р. | - Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы казначылык департаментының Саба районы территориаль бүлеге җитәкчесе (килешү буенча); |
| Габделмәнов Р.Н. | - “Сабантуй” балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе” өстәмә белем муниципаль бюджет учреждениесе директоры (килешү буенча); |
| Гайнетдинов Ш.Ә. | - район кулланучылар җәмгыятьләре берлеге идарәсе рәисе (килешү буенча); |
| Галиев А.Т. | - район электр элемтәсе узелы начальнигы (килешү буенча); |
| Галиев И.Г. | - “Ак Барс” Банкы ачык акционерлык җәмгыяте Казан филиалының Саба өстәмә офисы начальнигы (килешү буенча); |
| Галимҗанов Р.Х. | - “Энергосбыт” предприятиесе начальнигы (килешү буенча); |
| Галимуллин Р.Р. | - “Росгосстрах-Татарстан” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең Байлар Сабасы ш.т.б агентлыгы директоры (килешү буенча); |
| Галиуллин А.М. | - Саба муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе; |
| Гарипов И.Н. | - шәхси эшмәкәр (килешү буенча); |

| | |
|---|---|
| Гарипов И.Р. | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге начальнигы; |
| Гарипов М.Г. | - “Татавтодор” ачык акционерлык җәмгыятенең Саба филиалы начальнигы (килешү буенча); |
| Гарипов Р.Р. | - “Умырзая” эшкәртү-сату авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативы рәисе (килешү буенча); |
| Гәрәев А.Н. | - Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Гилманов Р.Г. | - Саба башкарма шәһәр комитеты җитәкчесе; |
| Гыйззәтуллин В.Н. | - “Саба урманчылыгы” дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе (килешү буенча); |
| Гомәров Р.И. | - “Ак барс страхование” ябык акционерлык җәмгыяте җитәкчесе (килешү буенча); |
| Дмитриев Б.Н. | - Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең Саба районы бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча); |
| Закирҗанов Р.Р. | - Саба муниципаль районы Башлыгы урынбасары; |
| Закиров И.Г. | - “Янгынга каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча 129 номерлы янгын часте” ФДКУ җитәкчесе (килешү буенча); |
| Зарипов А.Ә. | - “НП-Транс-Ойл” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча); |
| Зарипов И.Р. | - “Газводстрой” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча); |
| Зарипов Р.С. | - “Рамазан” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча); |
| Заһидуллин Р.Ф. | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге начальнигы; |
| Иванов М.Н. | - шәхси эшмәкәр (килешү буенча); |
| Ильясов Ф.И. | - районара почтамт начальнигы (килешү буенча); |
| Исламова Ә.М. | - “Аш-су” кулланучылар җәмгыяте директоры; |
| Исмәгыйлов В.Ш. | - Россия Федерациясе эчке эшләр министрлыгының Саба районы бүлеге начальнигы (килешү буенча); |
| Исмәгыйлов И.Ш. | - “Татарстан Республикасы гигиена һәм эпидемиология үзәге” сәламәтлек саклау федераль дәүләт учреждениесенең Саба, Кукмара, Мамадыш районнары филиалы баш табибы (килешү буенча); |
| Исмәгыйлов Р.Г. | - “Татмедиа” акционерлык җәмгыятенең “Саба таңнары” газетасы” филииалы баш мөхәррире (килешү буенча); |
| Йосыпов М.Р. | - район үзәк хастаханәсе баш табибы (килешү буенча); |
| Кәримов И.Җ. | - җаваплылыгы чикләнгән “Сабаагрохим” җәмгыяте директоры (килешү буенча); |
| Кәримов Р.И. | - “ФРГ” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча); |
| Кәримуллин Р.К. | - “Саба тәрәзәләре” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча); |
| Красавин С.В. | - “Евро Акцент Саба” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча); |
| Марченко Д.Б. | - “Саба сөт комбинаты” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча); |

| | |
|---|---|
| Миннебаев И.Р. | - “Саба машина-технология станциясе” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча); |
| Мөбәрәкова Ә.Г. | - “Татмедиа” акционерлык җәмгыятенең “Саба дулкыннары” телерадиокомпаниясе” филиалы директоры (килешү буенча); |
| Мөхетдинов И.И. | - “Газпром трансгаз Казань” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең “Сабагаз” эксплуатация-җитештерү идарәсе начальнигы (килешү буенча); |
| Насыйбуллин М.Н. | “Зерновозим” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры; |
| Нәбиуллин Ф.Ә. | - “ПМК-159” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча); |
| Нигамәтҗанова Г.Р. | - авыл хуҗалыгы сәнәгате комплексы профсоюзларының район комитеты рәисе (килешү буенча); |
| Нигъмәтҗанов Ф.Ә. | - “Сабагро” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча); |
| Нуриев Ф.Я. | - Бөтенроссия ирекле янгын җәмгыятенең Саба район һәм шәһәр бүлекчәсе начальнигы (килешү буенча); |
| Сидорук В.М. | - “ТАТМИТ Агро” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча); |
| Сөнгатов Ш.Ә. | - Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе; |
| Сөнгатуллин Р.Р. | - “Татарстан Республикасы техник инвентаризация бюросы” акционерлык җәмгыятенең Саба бүлекчәсе начальнигы (килешъ буенча); |
| Талипов И.И. | - “Саба “Мелиорация” механикалаштырылган күчмә колоннасы” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча); |
| Фатыйхов Н.И. | район электр челтәре начальнигы вазыйфасын башкаручы (килешү буенча); |
| Фатыйхов Р.С. | - кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Саба, Мамадыш, Кукмара районнары территориаль бүлеге (Саба территориаль бүлеге) начальнигы (килешү буенча); |
| Хаҗиев И.Р. | - “Сельхозснаб” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча); |
| Хәбибрахманова В.А. | - балалар иҗат үзәге директоры (килешү буенча); |
| Хәбибуллин И.Г. | - “Торак-коммуналь хуҗалыгының Саба күптармаклы җитештерү предприятиесе” ачык акционерлык җәмгыяте директоры (килешү буенча); |
| Хәбиров Н.Г. | - “Таиф-НК АЗС” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча); |
| Хәсәнов Р.М. | - Саба шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| Хисамов Р.Р. | - “Олимп” балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе муниципаль учреждениесе директоры (килешү буенча); |
| Хуҗин М.М. | - Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Саба муниципаль районы социаль яклау бүлеге начальнигы (килешү буенча); |

| | |
|---|---|
| Хурамшин Ф.Ш. | - “Агропромснаб” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча); |
| Шакиров И.Ф. | «Саба муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф идарәсе” муниципаль бюджет учреждениесе начальнигы |
| Шәймәрдәнов М.Т. | “ЯРДӘМ” фонды директоры; |
| Шәйхуллин А.Н. | - “Саба район дәүләт ветеринария берләшмәсе” дәүләт бюджет учреждениесе начальнигы (килешү буенча); |
| Шәрәфиева Ф.М. | Россия саклык Банкының 4642 номерлы Саба бүлекчәсе идарәчесе (килешү буенча); |
| Шәфыйков А.В. | - федераль салым хезмәте Татарстан Республикасы буенча 10нчы номерлы районара инспекциясе җитәкчесе (килешү буенча); |
| Якупова Ф.Ш. | - Россия Федерациясе Пенсия Фондының Татарстан Республикасы Саба һәм Теләче районнары буенча идарәсе начальнигы (килешү буенча); |
| Яхин А.А. | - “Сабэнергосервис” җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча). |